# Сүзлекләр һәм алардан файдалану күнегүләре

Бик күп телләрне белсә дә,
Сөйләшми бер телдә дә,
Өйрәним дисәң, өйрәтә,
Карышмый беркемгә дә

# Максат:

1*. Лексикография фәне турында гомум төшенчә бирү;*
*2. Сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен өйрәнү,*
*3. Ишетеп аңлау, сөйләм, язу күнекмәләрен   үстерү;*
*4. Китапка  сакчыл караш булдыру*

Сүзләрне туплау, тәртипкә салу һәм сүзлекләр төзү турындагы фәне **лексикография** дип атыйлар.

**Китап  галим - телсез мөгаллим.**

**Бирем:**

“Татар теленең орфографик сзлеге”н ачып бу сүзләрнең дөрес язылганын дәлилләп дәфтәрләрегезгә языгыз.

**Бирем:**

*Китап, галим, мөгаллим* сүзләрен “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” ннән Карап мәгънәләрен табыгыз, дәфтәрегезгә күчереп языгыз.

**Бирем:**
*Мөгаллим, галим*
сүзләренең синонимнарын
“Синонимнар сүзлеге”ннән
табыгыз.

**Китаплар озак яшәсеннәр:**

-Китапны урталай бөкләргә ярамый.
-Аның битләрен бөкләп куярга ярамый.
-Китап эченә каләм тыгып калдырырга ярамый.
-Китапка язарга һәм рәсем ясарга ярамый.
-Китапны пычрак кул белән тотарга ярамый.
-Ашаганда китап тотып утырырга ярамый.
-Китапны кояш нурлары төшкән җирдә укырга ярамый.
-Китап битләре кояш нурларыннан, пычрактан, юештән бозылалар. Аларны тагын тузаннан һәм корткычлардан сакларга кирәк.
-Китапларны чиста парталарга һәм өстәлләргә генә куярга кирәк.
-Бер битне укып бетергәч, алдагы битне өстәге почмагыннан гына тотып ачарга гадәтләнегез. Һәм беркайчан да бармакларыгызны төкерекләмәгез.

| | | |
|---|---|---|
| Китап | Книга | Book |
| Мәгаллим | | |
| Телсез | | |
| Галим | | |

Бирем:
*уй, тел* сүзләрен
Нәкый Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге”ннән табыгыз, аңлатмалары белән күчереп языгыз.

***Татар теленең***
***Орфографик сүзлеге***
***Аңлатмалы сүзлеге***
***Синонимнар сүзлеге***
***Ике телле һәм күп телле***
***тәрҗемәле сүзлекләре***
***Фразеологик сүзлеге***

Эшегез өчен рәхмәт!

